КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 март г.Казань № 227

**Татарстан Республикасы территориясендә, «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Цифрлы инновацияләр өлкәсендә экспериментал хокукый режим билгеләү һәм Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү инициативасын гамәлгә ашыруга карата гражданнарның сәламәтлеге һәм диагнозлары турында белешмә җыю һәм эшкәртү буенча «Персональ медицина ярдәмчеләре» технологияләрен кулланыла торган медицина эшчәнлеге юнәлеше буенча цифрлы инновацияләр өлкәсендә экспериментал хокукый режим программасын раслау турында» 2022 елның 9 декабрендәге 2276 номерлы карарының 34 пунктын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 28 декабрендәге 2469 номерлы карарының 9 пунктын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә, «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советын төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә, «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советы турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы территориясендә, «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советын;

Татарстан Республикасы территориясендә, «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыруда катнашучы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары исемлеген.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә әлеге пилот проектын гамәлгә ашыруда катнашуны тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 10 март, 227 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы территориясендә, «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә, «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советы (алга таба – шул ук эзлеклелектә пилот проекты, Координация советы) эшчәнлеген регламентлаштыра.

1.2. Координация советы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокукый режим билгеләү һәм Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү инициативасын гамәлгә ашыруга карата гражданнарның сәламәтлеге һәм диагнозлары турында белешмә җыю һәм эшкәртү буенча «Персональ медицина ярдәмчеләре» технологияләрен кулланыла торган медицина эшчәнлеге юнәлеше буенча цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокукый режим программасын раслау турында» 2022 елның 9 декабрендәге 2276 номерлы карарын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 28 декабрендәге 2469 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында төзелгән киңәшмә һәм координацияләүче орган булып тора.

1.3. Координация советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Координация советының төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Координация советының төп бурычлары:

пилот проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

пилот проектын гамәлгә ашырганда оптималь карарлар кабул итүне тәэмин итә торган тәкъдимнамәләр һәм тәкъдимнәр эшләү;

пилот проектын гамәлгә ашыруда катнашучы республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка кызыксынучы органнар һәм оешмалар эшчәнлегенең үзара хезмәттәшлеген оештыру.

2.2. Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында Координация советы түбәндәге функцияләрне башкара:

пилот проектын гамәлгә ашыруда катнашучы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары (алга таба – медицина оешмалары) эшчәнлеген координацияли;

пилот проектын гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар формалаштыруга ярдәм итә;

пилот проектын гамәлгә ашыруга бәйле башка мәсьәләләрне хәл итә.

## III. Координация советы вәкаләтләре һәм хокуклары

3.1. Үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен координация советы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

пилот проектын гамәлгә ашыруга бәйле карарлар кабул итә;

пилот проектын гамәлгә ашыру барышы турында квартал саен бирелә торган хисаплар составында башкарылган эш нәтиҗәләре турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына мәгълүмат бирә;

пилот проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар эшләүдә катнаша.

3.2. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Координация советы түбәндә-геләргә хокуклы:

Координация советы эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләрен, Координация советы составына кермәгән медицина оешмалары җитәкчеләрен җәлеп итәргә;

медицина оешмаларына методик һәм консультатив ярдәм күрсәтергә;

үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы медицина оешмаларыннан Координация советының пилот проектын гамәлгә ашыруга бәйле карарларны кабул итүе өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга.

## IV. Координация советының эш тәртибе

4.1. Координация советы пилот проекты рәисе, рәисе урынбасары, кураторы, Координация советы секретаре һәм әгъзалары составында төзелә. Координация советв рәисе – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары.

4.2. Координация советы рәисе Координация советы эше белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра; Координация советы утырышлары беркетмә-ләренә һәм Координация советының башка документларына кул куя; Координация советы әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә; Координация советы утырышларының көн тәртибен һәм Координация советының эш планнарын раслый; Координация советы әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

4.3. Координация советы рәисе урынбасары Координация советы рәисе урында булмаганда аның вазыйфаларын башкара; Координация советы утырыш-ларында карала торган мәсьәләләрне әзерләүне тәэмин итә.

4.4. Пилот проекты кураторы пилот проектын гамәлгә ашыруны контрольдә тота.

4.5. Координация советы секретаре Координация советы утырышларын оештыру һәм техник яктан әзерләүне, Координация советы карарларын

рәсмиләштерүне тәэмин итә; Координация советы әгъзаларына һәм чакырылган затларга Координация советы утырышларының урыны, датасы, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, Координация советы утырышлары беркетмәләрен алып бара, аңа Координация советы рәисе тарафыннан йөкләнгән башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

4.6. Координация советы әгъзалары Координация советы утырышларында һәм Координация советы утырышларында карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнаша, Координация советы утырышларында карап тикшерелә торган документларны һәм материалларны карауга кертә, Координацион совет рәисенең Координация советы әгъзасы буларак эшчәнлек гамәлгә ашыруга бәйле йөкләмәләрен үти, Координация советы утырышында катнашу мөмкинлеге булмаганда үз вәкаләтләрен вәкаләтле вәкилгә тапшыра (бу хакта алдан ук Координация советы рәисенә хәбәр итә), Координация советының чираттан тыш утырышы турында, көн тәртибенә фикер алышуга мәсьәләләр кертү турында тәкъдимнәр кертә, Координация советының пилот проектын гамәлгә ашыруга бәйле карарларын кабул итүдә һәм үтәүне оештыруда катнаша.

4.7. Координация советы утырышлары Координация советы рәисе карары буенча, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Координация советы әгъзалары Координация советының чираттан тыш утырышын үткәрү турында тәкъдимнәр кертергә һәм көн тәртибен тәкъдим итәргә хокуклы.

4.8. Координация советы утырышын үткәрү датасы һәм аның көн тәртибе Координация советы рәисе тарафыннан раслана.

4.9. Координация советы утырышын Координация советы рәисе алып бара.

4.10. Координация советы эшендә кирәк булганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләре, Координация советы составына кермәгән медицина оешмалары җитәкчеләре катнаша ала.

4.11. Координация советы карарлары Координация советының утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

4.12. Координация советы карарлары киңәш бирү характерын йөртә, беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аларга Координация советы рәисе тарафыннан Координация советы утырышы үткәрелгән көннән өч эш көне эчендә кул куела.

4.13. Координация советы иҗтимагый башлангычларда эшли.

___________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 10 март, 227 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә,
«Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру буенча координация советы
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Координация советы рәисе |
| Абашев Әлмир Рәшид улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары, пилот проекты кураторы, Координация советы рәисе урынбасары |
| Савина Анна Игоревна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсенә караган дәвалау ярдәме бүлегенең төп консультанты, Координация советы секретаре |

Координация советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әмиров Рафаэль Илдар улы | «Витакор» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Багданова Ольга Георгиевна | Казан шәһәренең «7 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы |
| Ваһапова Гөлнар Рифат кызы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгече – эндокринологы |
| Гайфуллина Гөлнара Ренад кызы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсе башлыгы |
| Гарифуллин Линар Рөстәм улы | «МедМаркет» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гыйльманова Гүзәлия Әнәс кызы | «Казан эндокринология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы |

| | |
|---|---|
| Делян Артур Маркосович | Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы |
| Ким Зульфия Фәрит кызы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгече – кардиологы |
| Мифтахова Алсу Мансур кызы | «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе директоры |
| Нурмиев Марат Сәйдәш улы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының мәгълүмат һәм инновацион технологияләр бүлеге башлыгы |
| Савинов Сергей Юрьевич | Казан шәһәренең «10 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы |
| Тихомиров Василий Борисович | «Телемедицина мәгълүмат системалары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Ханов Рөстәм Флюр улы | Яр Чаллы шәһәренең «7 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы |
| Шаһвәлиева Резида Әрхәметдин кызы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсенә караган дәвалау ярдәме бүлеге башлыгы |
| Шерпутовский Владимир Георгиевич | «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе директоры. |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 10 март, 227 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә, «Персональ медицина ярдәмчеләре» мәгълүмат системасыннан (платформасыннан) файдаланып, пациентның сәламәтлеген дистанцион күзәтү буенча пилот проектын гамәлгә ашыруда катнашучы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары исемлеге

1. «Казан эндокринология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
2. Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
3. Казан шәһәренең «7 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
4. Казан шәһәренең «10 нчы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
5. Яр Чаллы шәһәренең «7 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.

___________________________